
Чыраҕы нур сибә бүген дә

(Таҗетдин Ялчыголның тууына 240 ел)



Таҗетдин Ялчыгол.

Кырлай авылыннан Җаек (Уральски) каласына алырга килгәндә «мин ян тәрәзә төбендә “Рисаләи Газизә” укып утыра идем», — дип язып үтә Г. Тукай үзенең «Исемдә калганнар» әсәрендә.

Һәр китапларның арасында
Сөеп укыганым «Газизә»
Салкын йөзләрдин, җаман сүздин
Бәнем җан гынаем да бик бизә.

1860 нчы елларга караган бер кулъязмада әнә шундый юллар бар. Биредә дә сүз шул ук «Рисаләи Газизә»* китабы турында бара.

Филология фәннәре докторы, профессор Габдрахман Таһиржанов: «Рисаләи Газизә» кулъязма килеш бик күп таралудан тыш әллә ничә тапкырлар басылган да, һәм ул дистәләрчә мәртәбәләр нәшер ителгән «Кыйссаи Йосыф», «Кисекбаш», «Бәдәвам», «Нәсихәт-әс-салихин», «Рәүнәкъ-әл-ислам» китаплары белән бергә авыл мәдрәсәләрендә дәреслек булып хезмәт иткән»[1], — ди.

Г. Рәхим белән Г. Газиз дә аны «безнең татарның бик яратып укый торган китапларыннан берсе»[2], — диләр. «Казан утлары» журналының 1966 елгы

* Китап беренче тапкыр Санкт-Петербургта бастырылган. Мондый мәгълүмат бирелгән: Таҗетдин Ялчыгол угълы. Рисаләи Газизә (шәрхе «Сөбат-әл-гажизин»). – СПб. Нижний губернасы Сергач өязе, Ендовище волосте Пар авылының Ризван Малай (Мәләү. — *Д. Г.*) харәҗәте илән, 1847 (1263). – 372 б. Китап Казанда беренче тапкыр 1850 елда дөнья күргән.

1 санында Н. Исәнбәт язуына караганда, бу китап Тажетдин Ялчыгол угылы тарафыннан язылган.

Кем соң ул Тажетдин Ялчыгол?

Аның турында элек тә, хәзер дә матбугатта мәгълүматлар чыгып тора. Ул Ш. Мәржани, Р. Фәхретдинов кебек мәшһүр галимнәрнең игътибарыннан читтә калмаган. Әдәбиятчылардан Г. Рәхим, Г. Газиз аның иҗатын өйрәнгәннәр. Соңгы чорда А. Фәтхи, М. Госманов, Х. Миңнегулов, М. Әхмәтҗанов, М. Гайни-Лабити хезмәтләрендә Тажетдин Ялчыгол иҗаты чагылыш таба. Башкортстанда Ә. Харисов, И. Галәветдинов һәм башкалар аның хакында, әсәрләренең теле турында язып чыктылар.

Г. Ибраһимов аны «ике халык арасыннан чыккан», ягъни татар һәм башкорт халкы арасыннан күтәрелгән әдипләр рәтендә искә ала[3]. Г. Рәхим һәм Г. Газиз тарафыннан төзелгән «Татар әдәбияты тарихы»нда аның турында күп мәгълүмат бирелсә дә, аларның шактый төгәлсезлеген күрсәтергә кирәк. Мәгълүм булганча, Тажетдин Ялчыгол үзен «Рисаләи Газизә» китабында «аз азыклы, күп языклы Көдәй халкының галиме» дип атый. Шуннан чыгып Г. Рәхим белән Г. Газиз «Көдәй» Тажетдиннең «ихтимал мулла булган авылының исемедер»[4], — диләр.

Профессор Г. Таһирҗанов та «Кәди халкының» дигәндә бу сүз артына сорау билгесе куя. Ә Ә. Харисов китабында әлеге сүз юл хәрефеннән башланган «гидай» сүзенә әверелгән. Монда инде «гидай» — теләнче, хәерче, саилче, ярлы дигәннәрне аңлата, ягъни Тажетдиннең ниндидер ярлы, хәерче халыкның галиме дип аңларга тиеш булабыз.


Чынлыкта исә, Көдәй бер ыруның исеме. Мәсәлән, XVII-XVIII гасырларда бу ыру дүрт нәселне: Төрекмән Көдәй, Урман Көдәй, Шайтан Көдәй һәм Бәләкәй Көдәй нәселләрен берләштергән. Берничә йөз элек бу ыру Әй елгасы буенда яшәгән Әйләләр составына кергән. Әйле ыруының шәҗәрәсенә караганда, Т. Ялчыголның дистәләгән төп бабасы әнә шул Әй елгасы буенда тереклек кылган*.

Аның хакында безгә мәгълүм булган биографик мәгълүматлар бай булмасалар да, алар бу шәхесне асылда аңлау һәм аны үзе яшәгән иҗтимагый шартларга куеп, шул чор сыйныфларының ихтыяҗлары белән бәйләнештә караганда, аның тормышының төп мәгънәсен дөрес билгеләү өчен җитәрлек дип әйтә алабыз.

Тормыш төрле һәм катлаулы булган кебек, тарихи шәхесләрнең дә язмышы катлаулы һәм төрлечә. Кайчакта шулай була ки, аларның кайберләре турында әйтелергә тиешле уңай фикерләр әйтелмичә кала. Чөнки аларны әйтүдән әлеге шәхесләрнең шәхси тормышларындагы кайбер нюанслар тоткарлый.

Соңгы вакытта Тажетдин белән дә шулайрак килеп чыкты. 1972 елны Казанда чыккан М. Госмановның «XVII-XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары» дигән китабында «Тәварихы Болгария» әсәренә багышланган бүлектә язучыга карата тирән эзләнүсез бирелгән бәя нәтиҗәсендә, Тажетдинның «ачы бал эчеп кинәт кенә үлүе турында»гы хәбәре — «исерек хәлендә үлгән» дигән «сенсация»гә әйләнә. Әйдәгез, асылына төшенеп карыйк. Ш. Мәржани аның турында болай яза: «Сәяхәте вакытында дусларыннан берәүнең йортына кереп эчәргә сорады, өй хуҗасы ачы бал китереп биреп, шуны эчеп кинәт кенә Имәнле исемле авылда вафат булып, каберлегендә күмелде»[5]. Р. Фәхретдинов Тажетдиннең 1838 елның 26 июнендә (Һиҗри белән 1254 ел, рәбигыль-ахир аеның 14нче көнендә) үлүен генә яза[6]. Вафатының ни сәбәптән икәнен телгә алмый. Югыйсә, ул да бит Ш. Мәржанине кабатлый алгандыр. Мәсьәлә монда катлаулырак. Җимешле агачка таш аталар дигәндәй, үзе муллалык иткән авылдан 30-40 чакрым читтә кинәт кенә үлгәнлектән, заманында аның үлүе хакында төрле авылда төрле хәбәр таралган. Шундый хәбәрләрнең берсе: исереп, эчеп үлүе хакындагысы Тажетдинне күрә алмаган муллалар, мөәззиннәр тарафыннан күпертелеп җибәрелүе дә гажәп түгел. Мөгаен, әнә шундый хәбәр

* Тажетдин Ялчыгол нәселеннән килүче, Казанда яшәүче Нәкыя апа Сәфәровадa (Татарстан эчке эшләр министры Ә. Сәфәровның әнисе) галимнең казанлылар ясаган шәҗәрәсе бар. Анда Тажетдинның туу урыны итеп Олы Әтнә ягындагы Ашыт суы буендагы Шимбер авылы күрсәтелгән. Бу зур ялгышлык.



Тажетдин Ялчыголның шәҗәрәсе.

Ш. Мәржанигә да барып ишетелгәндер. Ә инде айлар, еллар үткәч, хакыйкать өскә чыккан һәм Р. Фәхретдинов дөреслекне аңлаган хәлдә, мәсьәләне күпертеп торуны кирәк тапмаган, шуңа күрә аның кайсы авылда, кайчан үлүе турында гына хәбәр иткән.

1914 елның 27 апрелендә «Шура» журналына җибәрү өчен язылган «Мөдафәга»да*: «...Зәй буе тарафларына барып кайтканда Тажетдин Имәнлебаш дигән авылда Габдессәлам дигән бер танышына кунарга керә. Иртән намазга барып кайтканнан соң, алар чәй эчәргә утыралар. Шунда бер касә чәй эчеп, әллә нигә кәефем үзгәреп тора әле дип ястыкка таянып тора һәм озак та тормый үлеп тә китә», — дип язылган. Аны Югары Мәлем авылының имамы, Тажетдин оныкларыннан берсе Һидиятулла Тажетдинов бабасының үлемен үз күзләре белән күргән Вәлид дигән кеше авызыннан үзе ишеткән буенча язган.

Менә болардан чыгып, без Т. Ялчыголның кинәт кенә үлүен әйтә алабыз.

Тарихтан билгеле булганча, Тажетдин яшәгән дәвердә бигрәк тә төрки халыклар арасында феодализмга хас йомыклык, караңгылык, томаналык һәм дини фанатизм бик нык хөкем сөрә. Патша Россиясе алып барган реакцион сәясәт татар һәм башкорт халкындагы иҗтимагый фикер үсешен нык тоткарлый. Халык массалары реаль тормышта аз гына да бәхет чаткылары әсәрен күрмәгәч, чын бәхетне, рәхәтне — хыялый теге дөньядан өмет итә. Суфыйчылык, ишанлык кебек күренешләрнең тамыр җәюен дә нәкъ әнә шуның белән аңлатырга кирәк.

Табигый, замандашларының күпчелеге шикелле, Тажетдин дә үзенең дөньяга карашы белән идеалист. Аның карашының нигезен ислам идеологиясе тәшкил итә. Ул җирдәге тормышны «фани», хыялдагы теге дөньяны «бакый» — «мәңгелек» дип тану принципларыннан чыгып эш итә. Шул ук вакытта аның иҗатында дөньяви фикерләр дә күп.

Тажетдин 1768 елда туа, яшьлек елларын туган җиреннән читтә үткәрә, димәк, тормышка мөнәсәбәте дә туган җиреннән читтә формалаша. Шуңа күрә аның идеяләрен, фикерләрен тулырак аңлау өчен ул гизгән һәм булган дәүләтләрнең шул чордагы хәлен өйрәнергә кирәктер.

Без аның кайда һәм күпме торуы хакында нигездә үзе язганнарга таянып фикер йөртәбез. «Тәварихы Болгария» дигән әсәрендә («Тарихнамәи Болгар» исеме белән дә билгеле) ул үзенең шәҗәрәсен яза. Бу әсәр безгә теге яки бу дәрәҗәдәге тарихи чыганак буларак кына түгел, авторының үзе турында китергән мәгълүматлар җәһәтеннән дә кызыклы. Дөрес, әлеге хезмәтендәге шәҗәрә 1897 елда М. Өметбаевның «Ядкарь» дигән китабында басылып чыккан. 1960 елда Уфада басылган «Башкорт шәҗәрәләре» дигән китапта (төзүчесе Р. Г. Кузеев) бу шәҗәрәнең бераз үзгәртелгән, 1912 елда кулдан күчерелгән варианты «Башкортларның әйле ыруы шәҗәрәсе» исеме астында бирелгән.

Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең кулъязмалар бүлегенә татар археографы С. Вахиди тупланмасыннан кергән бер кулъязмадагы (587 сакл. бер.) шәҗәрәдә Тажетдиннең үзе турында тагын да тулырак мәгълүмат китерелгән.

М. Өметбаев һәм С. Вахидиләрдә китерелгән шәҗәрәдә Тажетдиннең читтә атасы белән бергә 17 ел 8 ай 3 җомга (атна) булганы язылган. Шуның 14 елын ул Дийарбәкердә (Төркиядә) хаҗга киткән әтисен көтеп уздыра.

Әлбәттә, үткен зиһенле Тажетдин кул кушырып кына ятмаган, ул үзлегеннән күп укыган, мәдрәсәләрдә дәресләр тыңлаган һәм үзе дә дәресләр бирерлек булып өлгергән. Бу җәһәттән филология фәннәре кандидаты кавказлы С. Акбиевнең: «Әйтик, 1768-1838 елларда Жаксай шәһәрендә Тажетдин Ялчыгол исемле татар мөгаллиме укыткан»[7], — дип язып чыгуы әһәмияткә ия. Дөрес, бу даталар Тажетдинның туу һәм үлү вакытын күрсәтәләр. Аның Жаксайда XVIII гасырның 80нче

* Мөдафәга — яклау язуы. Югары Мәлем авылы имамы, Тажетдин Ялчыгол нәселеннән килүче Һидиятулла Тажетдинов тарафыннан язылган әлеге мөдафәганың күчермәсе авторда саклана.

еллары тирәсендә укыткан булуы мөмкин. Әмма ни генә булмасын, 15-16 яшьлек Таҗетдиннең кумык балаларының мөгаллиме булуы игътибарга лаек. Бу уңайдан Ә. Харисовның «Башкорт халкының әдәби мирасы» дигән китабындагы бер искәрмәне искә төшерик. Анда сүз М. Өметбаевның югарыда телгә алынган китабында Т. Ялчыгол турында язылган мәгълүматлар турында бара: «М. Өметбаев (ә аңа карап Р. Фәхретдинов) Таҗетдинның атасы 1200 (1785) елда үлгән дип күрсәтә. Әмма бу дата Таҗетдин Ялчыголов хакындагы башка биографик мәгълүматлар белән ярашмый. Өметбаев китергән датага караганда, атасы үлгәндә Таҗетдинга 18 яшь була, ә шул гомер эчендә инде ул Дагстанда да укыган, Дийарбәкер каласында да 14 ел торган, аннан соң атасы белән бергә 4 елга якын сәяхәттә йөргән! Монда йә Ялчыголның үлгән елы дөрес әйтелмәгән, йә Таҗетдиннең Дийарбәкер каласында укыган вакыты арттырып күрсәтелгән (14 ел түгел, ә 4 ел гына булуы бик мөмкин)».

Ә. Харисовның шиге дөрес, әлбәттә. Әмма биредә гаеп М. Өметбаевта түгел. Таҗетдиннең атасы Ялчыголның 1200 (1785) елда вафат булуында шигебез юк, чөнки ул «Рисаләи Газизә» дигән китабын 1806 нчы елны төгәлли һәм аны буйга җиткән, укый-яза белә торган кызына багышлый. Таҗетдин әтисе үлгәч кенә өйләнә һәм кызы әлеге китап төгәлләнгәндә 15-20 яшьләрдә булгандыр дисәк, әтисе 1785-1800 елларда үлгән дигән нәтиҗәгә киләбез.

«Башкорт шәҗәрәләре» (Өфө, 1960) китабында «1708 Таҗетдиннән Бәһаветдин тугмышдыр. Сиксән җиденче [елында үлде]. Бәһаветдин хәзрәтләрдер» дигән юллар бар. Кушымтада әлеге шәҗәрәнең фотокопиясе бирелгән. Анда шакмаклы җәя эчендәге сүзләр юк. Минемчә, сиксән җиде (1887) Бәһаветдинның үлү вакытын дөрес күрсәтә. Димәк, ул Ялчыгол бабасы үлгәннән соң туган булып чыга. Әтисе Таҗетдин хәзрәт үлгәндә ул инде бишенче дистәне тутырып килгән.

Сәет Вахиди тупланмасыннан кергән кулъязмадан күренгәнчә, Таҗетдин Ялчыголның 4 малае, 3 кызы булган (Бәһаветдин, Җәлалетдин, Шәрхенетдин, Госаметдин, Бибинәфисә, Газизә, Җәмилә). Бәлкем әле Газизә иң өлкәне дә булмагандыр. Боларны искә алып торуның кирәге булмас та иде, ләкин безгә Таҗетдиннең ничәнче елны туган якларыннан әтисе белән чыгып китүен ачыклау бик мөһим. Кызганычка каршы, мәсьәләнең бу ягына моңа кадәр беркем дә игътибар бирмәгән.


Ышанганыбызча, Таҗетдинның әтисе һиҗри 1200 елда, ягъни хәзерге ел исәбе белән 1785 елда вафат була. Без бу датадан аларның сәфәр елларын алып ташласак, Таҗетдин белән атасының 1767-1768 еллар тирәсендә читкә чыгып китүләрен исәпләп чыгарабыз. Ләкин 1768 елда Таҗетдин дөньяга гына килгән. Әтисе үлгәндә аңа нибары 17-18 яшь кенә була. Әтисе күкрәк баласын иртәп чыгып китмәгән, билгеле. Хикмәт нәрсәдә соң? Безнеңчә, бу фәкать китап күчерүчеләр ялгышы.

Әлеге шәҗәрәләрдә әйтелгәнчә, Таҗетдин Төркиянең Дийарбәкер шәһәрендә әтисен 14 ел түгел, ә 14 яшенә кадәр, яки Ә. Харисов икеләнеп кенә күрсәтеп үткәнчә, 4 ел гына көткән булуы бик мөмкин.

Күп дигәндә Таҗетдин Дийарбәкердә әтисен 5-6 ел көткән булуы ихтимал, икенче төрле әйткәндә, аларның Кавказ-Төркия якларында 8-9 ел йөреп кайтулары мөмкин. Шулай фараз кылганда Таҗетдингә әтисе белән читкә чыгып киткәндә 8-11 яшь була. Ягъни бу 1775-1777 еллар тирәсенә туры килә.

Моңа хәзергә ачык дәлилләр юк. Алга таба Таҗетдин шәҗәрәсенең яңа күчермәләре, тәрҗемәи хәленә караган яңа язмалар табылу гына моңа ачыклык кертә ала. Әмма Таҗетдин нәселенең бүгенге вәкилләре арасында яшәп килгән бер риваять безнең фикеребезне куәтли төшә. Алар үзләренең ерак бабаларының (ягъни Таҗетдин әтисенең) «Пугачау явында» катнашуын һәм әлеге восстание бастырылгач, 1775 елларда җәзадан качып Кавказ ягына чыгып китүе турында сөйлиләр.

Таҗетдиннең үзе турында кайбер мәгълүматлар аның «Рисаләи Газизә» дигән китабында да бар. Бу китап 1796 елда язылган һәм үз дәверендә күче-



Тажетдин Ялчыголның Коръәне.

релә-күчерелә халык арасында киң таралган. Ул Бохара суфые Аллаярның (1713 елда вафат) «Сөбател-гаҗизин» (Көчсезләрнең ныклыгы) исемле шигъри әсәренә комментарий (шәрех) рәвешендә язылган. Китап исламны тануга һәм тотуга, аның тарихына, ахирәткә багышланган. Бер үк вакытта бу әсәрдә дөнья тормышына, әдәп-әхлакка карата да фикерләр әйтелгән, мәсьәләне тулырак яктырту өчен хикәятләр китерелгән. Боларның күбесен Тажетдин үзе өстәгән. Бәлкем нәкъ менә шуның өчен дә Ш. Мәржани «Рисаләи Газизә» авторының «Сөбател-гаҗизин»не ялгыш шәрехләве турында сүз алып барадыр.

Мәгълүм булганча, Аллаярның борынгы Идел буе төркисенә шактый якын, ләкин үзенә генә хас үзенчәлекләре булган «чыгтай шивәсендә»* язылган бу әсәренә Утыз Имәни дә 1782 елда гарәпчә шәрех яза.

Ләкин тегесе дә, бусы да киң массага рәхәтләнеп аңларлык булмый. Кешеләрнең бу әсәрне ана телләрендә аңлатып бирүе турында ялваруына Газизә исемле кызының үтенече дә өстәлгәч, Тажетдин бу китапка аңлаешлы төрки телендә тәфсилле аңлатмалар бирә. Бу китап шул чор мәктәпләрендә тел-әдәбият дәреслеге сыйфатында кулланылып йөргән. Язылып кырык елдан артык вакыт үткәч, (хәтта Тажетдин үзе үлеп 9 ел узганнан соң гына) ул 1847 елда Петербургта басылып чыга. Казан император университеты типографиясендә 1850 елда басыла һәм шуннан соң Казанда күп мәртәбә (соңгысы 1916 елда) бастырылып таратыла. Аның В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз китапханәсендә ундүрт басмасы саклана. «Рисаләи Газизә»нең язылу формасы эчтәлегенә тулысынча туры килә. Әгәр дә шигъри калыпта язылган Аллаяр тексты көйләп укыганда илаһилык төсе алып хискә тәэсир итсә, Тажетдин комментарийлары аз гына булса да дөньяви фикерләүне кузгатып җибәрәләр. Бу китапның халыкта күп таралуына һәм аның яратылып укылуына әнә шул сәбәп тә инде. Чөнки ул чын мохтажлыкта һәм караңгылыкта яшәгән кешеләргә әзме-күпме рухи азык биргән, якты тормышка өметләрен өздермәгән.

* Чыгтай шивәсендә — иске үзбәк телендә.

Тажетдин Ялчыгол проза өлкәсендә дә, шигърияттә дә шактый хәбәрдар булган. Ул, милли әдәбиятыбызда беренчеләрдән булып, татар кыллы инструментларына игътибар итә. Мәсәлән, Тажетдиннең Сарман районында табылган бер кулъязма әсәрендә татарлар арасында киң таралган гөслә, скрипка, думбра һәм әриләнең рәсемнәрен бирүе карашларының киңлеге, татар мәдәнияте белән якыннан таныш булуы турында сөйли[8].

Тажетдин нәселе кешеләре тапшырган иске кулъязмалар арасыннан табылган шигырьләр арасында улы Җәлалетдин хәзрәт язган бер шигырь аеруча игътибарга лаек*. Ул Тажетдин үлгәннән соң язылган. Һәр ике юллыкның беренче юлы баш хәрефләрен бергә җыйсаң «Вәләд Тажетдин» дигән сүз килеп чыга. Әлеге телестихта** Тажетдингә реаль бәя бирелгән. Бу шигырьдән аның Зәй буенда берничә еллар йорт-җир белән тереклек итүе, балаларының Кызыл илдә (ягъни Кызыл Чапчакта) үскәнлеге, Тажетдиннең исеме танылган булуы, бер үк вакытта аның диндар икәнлеге, күп китаплар өйрәнеп белем алуы һәм зур омтылыш белән дәрес бирүе әйтелгән. Шул үк вакытта дөньяны сөймәве һәм әһлене (биредә ил түрәләрен дип аңларга кирәктер) дус тотмавына басым ясалган. Бу юллар Тажетдиннең «Рисаләи Газизә»гә язган кереш сүзендә үзе турында «адәмиләр арасында дошман тотылган, барча эшне Ходага тапшырган» дигән сүзләре белән аваздаш яңгырыйлар.

Тажетдин Ялчыгол һижри 1240 елда Югары Мәлем авылына күчеп килгәч язган һәм «Тәфсире Сидрәт ел-мөнтәһа» дип аталган «Һәфтияк» тәфсиренең бер кулъязма нөсхәсендә шагыйрь һәм күренекле рухани Гали Чокрыйның (1828-1889) үзенең шәкертләре һәм укучылары өчен язылган бер шигыре теркәлгән. Ул заманында шактый танылган дин әһелләрен олылап язылган. Яртысыннан күбесе Тажетдин хәзрәт турында.

Нөссхан ли-туллабиһи вә тәлямизәтиһи***

Яраннар, булмагыз бикар тәэлифтә
Тырышың булсаңыз Румда, Хәләбтә.
Утыз Имәндә мулла Габдерәхим
Утырып түзмәгән, төзегән мәназыйм.

Симәктә Шаһиәхмәт мөштәһирең
Сөялеп ятмамыштыр, бәрык дәйәрдең.
Дәхи Чәләби дәйәры мулла Әхмәт
Даны чыкты тырышмакдин бәлягать.

Газизә сахибе мулла Тажетдин
Өязгә ат чыгарды җәһедү җәһеддин.
Аның тәдрис заманында өендә
Чирагы сүнмәгән дирләр төнен дә.

Төне-көне һәр каю фәндин китабы
Төзәтеп әйләмешдер мөстәтаби.
Ничә табда рисалә әйләмешдер,
Ничә мөшкилне тәсһил әйләмешдер.

Тияр аның кәмалинә берәүсе
Шәкәр-балдыр хәлвият дә барысы.
Аның каны нәвалендин ничә гам
Алыр бәһрә ничә ай да, ничә гам.

1785 елны әтисен хәзерге Мамадыш районына кергән Кече Сөн авылында җирләгәннән соң Тажетдин Кама аръягына чыгып шунда төпләнеп кала. Моның үз сәбәпләре бар. Беренчедән, аңа әтисе кабере тирәсеннән ерак китмичә йорт-җир белән яшәргә һәм елына ике мәртәбә каберенә зират кылырга васыять итә. «Тәварихы Болгария» әсәрендәге шәҗәрәдән күренгәнчә, «Шартларымны үтәмәсәң әбәд разый дәгелмен» дип кисәтә әтисе. Икенчедән, бу якларда аны якынрак аңлаучы халык була. Ул башта Кызыл Чапчак (Түбән Кама районы) авылында яши, крестьян балаларына дәресләр бирә. Шушы авылда өйләнә һәм балалары да шушында үсә. Соңыннан ул Югары Мәлем (хәзерге Зәй районы) авылына күчә һәм муллалык итә.

Имәнле авылында бу көннәргәчә «Һәфтияк»нең Тажетдин кулы белән язылган тәфсире сакланган булган. Ул аңлаешсыз, гарәп-фарсы телендә язылган популяр китапларга, төрки телләрне яхшы белгән хәлдә, гади халык

* Куен кесәсе дәфтәре битләренә язылган бу шигырьләр автордa сакланa.

** Телестих — шигырь юлларының баш хәрефләреннән аерым исемнәр яки сүзләр ясалучы шигырь.

*** Тәрҗемәсе: «үземнең укучыларыма һәм шәкертләремә күрсәтмә».



Тажетдин Ялчыголның шәхси мөһере. Татарстан Республикасы Зәй шәһәре музее фондында саклана.

аңларлык итеп шәрехләр (комментарийлар) язган. Мәсәлән, Р. Фәхретдинов «Асар» исемле хезмәтендә Мәржанинең «Тажетдин хәзрәт гаят кятиб, бу хәзрәт һәм җәяү йөрер бер зат иде, "Кафия" касыйдәсенә, "Тәгълимес-салат", "Шорутыс-салат" китапларына шәрехләр язды. Язуы мәргуп вә камил һәм гүзәл рәвештәдер»[9], — дигән сүзләрен китерә.

Димәк, Ш. Мәржани аның турында югары фикердә дә булган, гәрчә үзенең «Мөстәфадел-әхбар» китабында ул Тажетдиннең «мөстәфади фахиш илә галәтдер» ди, ягъни башка чыганаклардан алынып язылган әсәрләре начар һәм хаталы, ди. Галимгә, күрәсең, аның үзеннән өсти-өсти шәрехләве бик ошап бетмәгәндер.

Тагын моңа кадәр күтәрелмәгән бер нәрсәгә тукталып үтмичә булмый. Әдәбият тарихында Тажетдин Ялчыгол дип мәгълүм булган бу шәхеснең фамилиясе ничек булган? Яхшыкол дигән фикерне алга сөрүчеләр дә бар. Моңа этәрүче сәбәпләрнең иң зурысы — аның кабер ташындагы язмалар.

Зәй районының Имәнлебаш авылы зиратындагы кабер ташында аның Яхшыкол углы икәнлеге һәм 1838 елда вафат булуы бәян ителә. «Ташка басылган бу мәгълүматлар аның үлү елын («Башкорт шәҗәрәләре»ндә һәм кайбер башка чыганакларда ул 1837 ел дип күрсәтелә) төгәл күрсәтү белән бергә «Яхшыкол» дигән исеме турында уйландыра.

Тажетдин Ялчыголмы, әллә Тажетдин Яхшыколмы? Р. Фәхретдиновның «Асар»ында Тажетдиннең тәмамланган китаплары ахырында язып беркетелгән гыйбарәләре китерелгән (336-337 битләр). Анда ул Тажетдин бине Яхшыкол әл-Болгари әл-Иштәки формасында китерелә. Бер хатында профессор Г. Тәһиржанов Тажетдин хәзрәтнең хаттат Сәгъдетдин күчергән язмаларын күргәне булуын, анда Тажетдин Яхшыкол дип язылуын хәбәр иткән иде. Сәгъдетдин Тажетдиннең замандашы һәм дусты, аның белән бергә гәпләшеп, фикер алышып яшәгән Имәнлебаш авылы кешесе булырга тиеш. Авылдашларының әйтүенә караганда, ул «атаклы китап күчерүче» булган. Зиратта әле хәзер дә Тажетдин кабереннән 20 метр гына читтә, яше йөздән арткан куш чыршы астында «Сәгъдетдин бабай кабере» сакланган. Сәгъдетдин Тажетдин атасының исемен яхшы белгәндер дип әйтәсе килә. Әмма ул Яхшыкол, Ялчыгол исемнәрен бердәй күреп, бу исемнәр киләчәктә бәхәс тудырыр дип уйламагандыр да. Ә менә 1987 елда Сармашбаш авылы мулласы Н. Җәмилевтән табылган язучының таш мөһерендә дә «Тажетдин Ялчыкол углы» дип язылган. Бу инде яңа бәхәсләргә урын калдыра шикелле...

Тажетдин Ялчыгол үз халкын агартуга юнәлтелгән хезмәте белән искелекне чатнатуга, яра башлауга чөй кагучыларның берсе була. Ул чорның мәгърифәтчеләре, галим һәм укымышлылары йолдызлыгына күз салсак, мәдәни күгебезнең ярлы түгеллеген күрәбез. Тажетдин Ялчыгол да шушы йолдызлыкта үзенең исеме һәм урыны белән әдәбият тарихыбызга кереп калырга лаек... Ә моның өчен аны салкын йөзләрдән, яман сүзләрдән араларга кирәк. Әдәбиятчыларыбыз бу өлкәдә тиешле эш башкарырлар дип ышанып каласы килә.

СҮЗЛЕК:

Бәкрә — файда.

Бәлягать — сүз сөйләүдә яки язуда булган матурлык.

Бәрык дәйәрдең — яшен кебек ялтыравы.

Бикар — эшсез, файдасыз, бушка вакыт уздыручы.
Газизә сәхибе — Газизә хуҗасы, иясе. Сүз «Рисаләи Газизә» китабының авторы турында.
Гам — масса (халык).
Кан (кян) — рудник, карьер. Сүз Таҗетдин хәзрәтнең үзе казынып тапкан файдалы бүләкләре хакында.
Кәмаль — тулылык, өлгергәнлек, булуы җиткәнлек.
Мәназым — шигырь белән язылган хикәя мәгънәсендә. (Биредә сүз Габдерәхим Утыз Имәнинең Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» әсәренең күп санлы кульязмаларыннан бербөтен китап төзүен искә алган булса кирәк).
Мөстәтаби — күңелгә ятышлы әйбер.
Мөштәһир — атказанган, данлы, күренекле.
Нәвал — бүләк, бирелгән әйбер.
Өязгә ат чыгарды җәһедү җәһеддин — тырышлыгы белән өяздә дан алды, танылды мәгънәсендә.
Рум, Хәләб — шәһәр исемнәре.
Симәк — авыл исеме (хәзерге Мөслим районында).
Тәдрис — дәрес бирү, укыту.
Тәсһил — уңайлаштыру, җиңеләйтү.
Тәэлиф — җыйнау, төзү, китап (әсәр) язу.
Утыз Имән — авыл исеме.
Хәлвият — балланган (өлгереп җиткән) җимешләр.
Чәләби дәйяры — Чәләби (авыл, кала исеме, Чиләбе булырга мөмкин) хуҗасы.
Чираг — бүлмәне яктыртучы ут; лампа, шәм, чырак. Яктылык.
Яран — дус, иптәш.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Таһиржанов Г. Әдәби багланышлар һәм аларның нәтиҗәләре // Казан утлары. – 1975. – № 10. – Б. 131.
2. Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. – Казан, 1925. – Б. 156.
3. Ибраһимов Г. Әдәби тел мәсьәләсе яңадан күтәрелә // Кызыл байрак. – 1923. – 8 май.
4. Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. – Казан, 1925.
5. Мәржани Ш. Әл-кыйсьмес-сани мин китаби «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». – Казан, 1900. – Б. 250.
6. Фәхретдин Р. Асар. – Оренбург, 1904. – Б. 336.
7. Акбиев С. Габдулла Тукай һәм кумык әдәбияты // Казан утлары – 1976. – № 4. – Б. 140.
8. Монасыйпов Ш. Сызылып кына моң чыкканда // Казан утлары. – 1977. – № 2. – Б. 158.
9. Фәхретдин Р. Асар. – Оренбург, 1904. – Б. 336.

Фотолар авторның шәхси архивыннан.

Дамир Гарифуллин,
туган як тарихын өйрәнүче

РЕЗЮМЕ

Публикация историка-краеведа Д. Гарифуллина посвящена жизни и творчеству видного татарского писателя Таджеддина Ялчыгула (1768-1838).